СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**01 ноябрь 2024 ел** **№3**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында граждан-нарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында Казанка авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорты адресы буенча урнашкан Сурнар авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында Казанка авылы, Үзәк урамы, 18 нче йорты адресы буенча урнашкан Сурнар авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Үзәк, Чишмә урамнарында яшәүчеләр.

2 нче этап: Җиңү урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 275 сум тәшкил иткән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 550 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын,

хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм  җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә  тотылуына ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу; Үзәк һәм Җиңү урамнары арасындагы юлны яктырту);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 өчен чапкыч -мульчер сатып алуны өлешчә финанслашу);

- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (Казанка авылында яңа зиратны зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материал алу һәм аны кору)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен  җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ”                                        “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге  башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанка авылы, Җиңү урамы, 1нче йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанка авылы, Үзәк урам, 18 нче йорт.

7. Әлеге карар  басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы                                        В.Р.Габделхаков